**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 15 гыйнварындагы 31 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 сентябрендәге 3994 номерлы**
**«“Казанга гашыйк бул” иҗади проектлар конкурсын**
**уздыру турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Казанга гашыйк бул» иҗади проектлар конкурсын уздыру датасы үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 20 сентябрендәге 3994 номерлы «“Казанга гашыйк бул” иҗади проектлар конкурсын уздыру турында»гы карарының 1 номерлы кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.7 пунктта «2025 елның 15 гыйнварына кадәр» сүзләрен «2025 елның 30 апреленә кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 8.1 һәм 8.7 пунктларда «2025 елның 28 феврале» сүзләрен, тиешле килешләрдә куеп, «2025 елның 30 июне» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 8.2 пунктта «2025 елның 15 гыйнварыннан 2025 елның 20 февраленә кадәр» сүзләрен «2025 елның 5 маеннан 2025 елның 30 маена кадәр» сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 8.6 пунктта «2025 елның 20 февраленнән» сүзләрен «2025 елның 30 маеннан» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**